ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**08.12.2022 ел** **№ 1138**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Финан сминистрлыгының «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләренә һәм белгечләренә һәм шәһәр һәм авылҗирлекләре бухгалтерларына хезмәт хакы түләү турында» 2022 елның 09 августындагы 03-16/5605 хаты нигезендә һәм муниципаль берәмлек учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү системасын камилләштерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Башкарма комитетның «Биектау муниципаль районында үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре, муниципаль берәмлекләр Башкарма комитетларының баш бухгалтерлары һәм бухгалтерлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 29 маендагы 773 номерлы карары белән расланган«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты»МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Мәгариф бүлеге» МКУ,«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУүзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең айлык вазыйфа докладлары күләмен 2023 елның 1 гыйнварыннан арттырырга.

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» МКУнең Мәдәният бүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнеңМәгарифбүлеге» МКУ, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУнең Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ үзәкләштерелгән бухгалтерияләре җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» Нигезләмәсенең 3 пунктындагы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының үзәкләштерелгән бухгалтерияләр җитәкчеләре һәм белгечләре вазыйфаи окладлары»таблицасын түбәндәгередакциядә бәян итәргә:

| Җитәкче һәм белгеч вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булып торган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органы) структур бүлекчәсе (бүлеге)булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 31 800 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 30 200 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 30 200 |
| Бүлек башлыгы | 24 500 | 24 500 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 20 800 | 20 800 |
| Бухгалтер | 19 300 | 19 300 |

-Нигезләмәнең 4 пунктындагы 5пунктчасынтүбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5)билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә яисә муниципаль берәмлек бюджетында өстәмә керем булганда (хезмәткә түләү фондыннан тыш) эш нәтиҗәләре буенча премияләр. Премия күләме хезмәткәр эшчәнлеге нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән генә чикләнми.»

3.Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ruвеб-адрес буенча игълан итәргә.

5.Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ рәисенә йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин